**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

25.12.2015 Яр Чаллы № 3612

Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү
оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Тукай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләме турында»06.09.2015 ел, № 648 карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1 Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көненә 6 сум 50 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар ризык белән тәэмин итүне 11.01.2016 елдан 31.12.2016 елга кадәр оештырырга.

1.2 укучыларның кайнар туклануын оештыруга ата-аналар өчен айга 637 сум күләмендә түләү билгеләргә.

1.3 32 сум 00 тиенлек кайнар иртәнге аш оештырырга, шул исәптән 6 сум 50 тиенлек субсидия;

1.4 туклануны оештыруны контрольдә тотарга.

2. «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МБУ:

2.1 витаминнар, микронутриентлар белән баетылган төп туклыклы матдәләр күләме буенча балансланган иртәнге һәм төшке аш нормаларын һәм сыйфатын үтәүне исәпкә алу һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

2.2 укучыларның кайнар туклануын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

2.3 гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез керүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Мәктәп укучыларының кайнар туклануын оештыручы гомуми белем бирү оешмалары һәм башка предприятиеләр җитәкчеләренә:

3.1 санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм "гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" СанПин 2.4.5.2409-08, санитар кагыйдәләрне үтәүгә һәм санитар-эпидемиягә каршы (профилактик чараларны) үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү" СП 1.1.1058-01 нормативларына ярашлы рәвештә гомуми белем бирү

учреждениеләрендә кайнар туклануны оештыруга производство контролен үткәрү

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең мәгариф мәсьәләләре буенча урынбасары, Р.Р. Исаевка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Т. Гыйзәтуллина